**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422066, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Старая Икшурма,ул.Ленина,д.17
тел.8 (84362) 41-6-47

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8 (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
11.04.2023

КАРАР
№20

Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 6 маендагы 31 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 6 маендагы 31 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бухгалтерларның вазифаи хезмәт хакы түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазифа | Халык саны булган муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары | |
|---|---|---|
| | 3,5 меңгә кадәр кеше | 3,5 меңнән артык кеше |

| | | |
|---|---|---|
| Баш бухгалтер | 19 700 | 21 000 |
| Бухгалтер | | 18 000 |

»

1.2. 5 нче пунктның 5) нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) эш нәтиҗәләре буенча премия. Эш нәтиҗәләре буенча премия бер ай һәм квартал өчен исәпләнә ала. Премия күләме бухгалтер эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә, шулай ук һөнәри бәйрәмнәр һәм бәйрәм даталары (җирле үзидарә көне, Сабантуй, Республика көне, Яңа ел һ.б.) белән бәйле булырга мөмкин һәм максималь зурлык белән чикләнми. Премия түләү чыганагын күрсәтеп, тиешле норматив-хокукый акт булганда түләнә.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы А.И.Биккинин